**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Янил авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**13 ноябрь 2020 ел** **№7**

**«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 28 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2020 елның 29 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вахит авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Вахит авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;
- Вахит авылына һәм Вахит авылы мәдәният йортына видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Чишмә урамында суны боҗралау (кольцевание) (торба сатып алу һәм салу, экскаватор белән канау казу, горизонталь бораулау, кое өчен ЖБИ боҗра, су өчен краннар сатып алу), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- паркны карап тоту һәм территорияне җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, орлыклар һәм үсентеләр сатып алу, керү төркемнәре, төрле декоратив фигуралар, чыршы, Кыш Бабай һәм Кар кызы алу, ут белән бизәү), проект-смета документларын төзү, килешү буенча түләү;

- котлован (экскаватор эше, кыргый үсүче агачларны кисү, тамырын төпләү, чүп-чарны түгү, 2-3 метр тирәнлектә ясалма күл казу, туфракны җәю һәм чыгару, ком белән тигезләү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү.

- чишмәне төзекләндерү (территорияне куаклардан, агачлардан чистарту, чүп-чарны түгү, җәяүлеләр өчен тимердән юл салу, профтруба һәм тышлау өчен буялган калай табаклар (окрашенные листы) сатып алу, брусчатка, вак таш җәю, тутыкмас корычтан улак кую, керү юлларын ясау), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- хоккей тартмасын карап тоту һәм спорт инвентаре алу (территорияне куаклардан чистарту, мәйданчыкны тигезләү, су белән катыру, кардан чистарту, көрәкләр, инвентарь сатып алу, кәшәкәләр һәм чаңгылар, скандинавия йөреше өчен таяклар сатып алу, тренерга түләү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Ветераннар аллеясы өчен исемле табличка (килешү буенча табличка сатып алу)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Янил авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И. Х. Корбанов